СОВЕТ
НАЛАСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Вахитова, д. 64, с.Наласа,
Арский муниципальный район, 422018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАЛАСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
М.Вахитов урамы, 64 йорт, Наласа авылы,
Арча муниципаль районы, 422018

Тел. (84366)50-2-25, факс (84366)50-2-25. E-mail: Nalas.Ars@tatar.ru

«14» апрель 2020 г. №108

## Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Советы КАРАРЫ

### Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

"Наласа авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясына таянып, Наласа авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

Наласа авыл җирлеге Советының 2014 елның 27 октябрендәге 73 номерлы карары белән расланган (30.06.2015ел, №92; 26.10.2015ел, №7/1; 01.11.2016 ел, №26; 11.05.2017ел, №34; 07.09.2018 ел, №56; 09.10.2019 ел, №92 үзгәрешләр белән) Наласа авыл җирлеге уставына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

**1) 5 статьяга түбәндәге эчтәлекле 20 пункт өстәргә:**

20) Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә үзбелдекле төзелгән корылманы сүтү, үзбелдекле төзелгән корылманы сүтү яки аны рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын үзгәртеп коруның җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре, территорияне планлаштыру документлары белән билгеләнгән чик параметрларына яисә яисә федераль законнарда билгеләнгән мәҗбүри таләпләргә туры китерү турында карар кабул итү.»;

**2) 29 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«1. Җирлек Советы бермандатлы сайлау округлары буенча муниципаль сайлауларда сайланучы 7 депутаттан тора.»

**3) 30 статьяның 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«8. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясының 7_2нче өлеше нигезендә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә "Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның

биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында" 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, "Аерым категория затларга счетлар ачуны һәм аларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында акча һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) файдалануны тыю турында" 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәү фактлары ачыкланганда, Татарстан Республикасы Президенты (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) җирле үзидарә депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яисә депутатка карата башка җаваплылык чарасын куллану турында гариза белән тиешле карар кабул итәргә вәкаләтле органга яисә судка мөрәҗәгать итә.»;

**4) 30 статьяга түбәндәге эчтәлекле 8.1 пунктын өстәргә:**

«8.1. Үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат биргән җирле үзидарә депутатына карата, әгәр дә бу мәгълүматларны бозып күрсәтү җитди булмаса, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) депутатны муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында вәкаләтләренең вакыты беткәнче вазыйфасыннан азат итү;

3) даими нигездә вәкаләтләрен башкарудан вәкаләтләренең вакыты беткәнче даими нигездә вәкаләтләрен башкару хокукыннан мәхрүм итү юлы белән азат итү;

4) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында вәкаләтләренең вакыты беткәнче вазыйфаларны биләүне тыю;

5) вәкаләтләренең вакыты беткәнче даими нигездә вәкаләтләрен үтәүне тыю.»;

**5) 30 статьяга түбәндәге эчтәлекле 8.2 пунктын өстәргә:**

«8.2. Җирле үзидарә депутатына "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 7_3-1 өлешендә күрсәтелгән җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә муниципаль хокукый акт белән билгеләнә.».

2. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 15 көн эчендә уставларны теркәү һәм дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә башкарма хакимиятнең федераль органының территориаль органына җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге башлыгына "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында"гы карарны уставларны теркәү һәм дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә башкарма хакимиятнең федераль органының территориаль органыннан кергән көннән

соң җиде көн эчендә халык күпләп җыела торган урыннарда урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru).

4. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Наласа авыл җирлеге башлыгына карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң 10 көн эчендә үзгәрешләр һәм өстәмәләрне бастырып чыгару чыганагы һәм датасы турында уставларны теркәү һәм дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә башкарма хакимиятнең федераль органының территориаль органына белешмәләр җибәрергә.

Наласа авыл җирлеге
башлыгы: И.Р.Шакирова

СОВЕТ НАЛАСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «НАЛАСИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ИНН 1609003095